**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 20.06.2022** **№ 609**

## 2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы, Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү методикасы, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Биектау муниципаль районындагы социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының исәп нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында» 2021 елның 20 апрелендәге 75 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» НПнең 2022 елның 07 февралендәге 36 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» бәяләве нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1 Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 024 896 сум;
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 2 049 792,12 сум;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 3 074 688,18 сум;
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 4 099 584,24 сум;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 5 124 480,3 сум;
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 4 420 483,2 сум;
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 6 149 376,36 сум;

1.2 гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 28 701,11 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 28 701,11 сум;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 28 701,11 сум.

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенең торакны исәпкә алу һәм бүлү секторына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрне гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында исәпкә куйганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов